КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1042

2024 елда Татарстан Республикасында гражданн җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясе лауреатларына – социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга акчалата бүләкләү бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Рәисенең «2024 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премияләрен бирү турында» 2024 елның 1 ноябрендәге 835 номерлы Указын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясе лауреатларына – социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга акчалата бүләкләү бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 23 ноябрь, 1042 нче карары белән расланды

2024 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясе лауреатларына – социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга акчалата бүләкләү бирү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, гомуми таләпләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар алучыларны товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә һәм сайлап алуны уздыруга физик затларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Рәисенең «2024 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премияләрен бирү турында» 2024 елның 1 ноябрендәге 835 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе лауреатларына акчалата түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 ел, 26 февраль, 107 нче карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Раиса премиясе лауреатларына - социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга акчалата бүләкләү түләүгә субсидияләр рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2024 елда грантлар бирү механизмын билгели (алга таба - тиешенчә грантлар, премия лауреатлары).

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясен бирү турында» 2024 елның 1 ноябрендәге 835 номерлы Указының 1 пунктындагы 4 - 8 пунктчаларында күрсәтелгән премия лауреатларына грантлар Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе

премиясен гамәлгә кую турында» 2015 елның 3 июлендәге ПУ-619 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Рәисе премиясе турында нигезләмәнең 2 пунктындагы өченче абзац белән билгеләнгән күләмдә түләнә.

3. Грант бирү әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатка бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бюджет акчаларының баш бүлүчесенә - Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына (алга таба - Министрлык) җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Грант бирү алымы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

4. Грант турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

5. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган чыгымнар юнәлешләре:

гражданлык җәмгыяте өлкәсендә эшчәнлекне оештыру, проектларны (инициативаларны), фәнни тикшеренүләрне оештыруга, эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга бәйле эшләр һәм хезмәтләр сатып алуга чыгымнар (алга таба - чаралар);

чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру өчен кирәкле әйберләр, комплектлау әйберләре, материаллар, җиһазлар, программа белән тәэмин итү сатып алу;

мөлкәти хокукларны, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны сатып алу;

штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү;

транспорт хезмәтләре өчен түләү;

командировка чыгымнары, яшәү һәм туклану чыгымнары;

ягулык-майлау материаллары сатып алу;

элемтә хезмәтләре өчен түләү;

бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәрен, җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминият буенча кертемнәрне, дәүләт пошлиналарын, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри бүлеп алып калынган суммаларны һәм түләүләрне түләү;

чараларны эшләүгә һәм гамәлгә ашыруга бәйле башка чыгымнар.

6. Грант бирү турында килешү (алга таба - килешү) төзү планлаштырыла торган айның 1 числосына премия лауреаты түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентtan арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия

Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Берләшкән Милләт Оешмасы уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында Берләшкән Милләт Оешмасының Куркынычсызлык Советы яки Берләшкән Милләт Оешмасының Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатка Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы булмау яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмау;

башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

үзгәртеп оештыру (премия лауреатына башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәсә, премия лауреатының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган.

7. Грант алу өчен премия лауреаты Министрлыкка түбәндәге документларны үз эченә алган грант бирүгә гариза (алга таба - гариза) тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча грант алуга гариза;

гамәлгә кую документларының күчермәләре;

премия лауреаты җитәкчесе вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләрен;

грант күчерү өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счеты реквизитларын күрсәтеп, премия лауреаты җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (баш бухгалтеры булганда) тарафыннан имза куелган, премия лауреаты мөһере белән расланган белешмә кагазен (ирекле формада);

әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында премия лауреаты җитәкчесе кул куйган белешмәне.

Документлар премия лауреаты тарафыннан кәгазьдә тапшырыла.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр, премия лауреаты җитәкчесе яки ул вәкаләтләр биргән зат имзасы белән расланган һәм мөһере белән беркетелгән төзәтмәләрдән тыш, рөхсәт ителми. Гаризаның барлык битләре тегелгән, номерланган, премия лауреаты җитәкчесе яисә ул вәкаләт биргән зат имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

Бирелә торган мәгълүматларның дөреслеге өчен премия лауреаты Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

8. Премия лауреаты үз теләге белән Министрлыкка түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазе күчермәсен;

салым органында исәпкә кую турында документ күчермәсен;

салым органы белешмәләре нигезендә белешмә булдыру датасына торышына салым органы мәгълүматлары нигезендә телекоммуникация каналлары буенча яисә салым түләүченең шәхси кабинеты аша электрон рәвештә яисә Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүче (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәләрен үтәү турында белешмә формасын һәм аны электрон рәвештә тапшыру форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәләрен үтәү турында белешмә;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Премия лауреаты тарафыннан бу пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

9. Гариза Министрлык тарафыннан заявкаларны теркәү журналына кергән көнне теркәлә.

10. Министрлык гариза теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә премия лауреатын һәм аларга тапшырылган документларны әлеге Тәртипнең 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүне тикшерә һәм грант бирү яисә грант бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Министрлык кабул ителгән карар турында премия лауреатына ул кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә гаризада күрсәтелгән электрон почта яисә башка контактлы реквизитлар ярдәмендә карар турында хәбәр итә.

11. Премия лауреатына грант бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

преми лауреаты тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

премия лауреаты тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнү.

12. Грант Министрлык һәм премия лауреаты арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма буенча килешү нигезендә бирелә. Килешү грант бирү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

грант күләме, аның максатчан билгеләнеше;

грантны күчерү тәртибе;

грант бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм грант бирү нәтиҗәсенең соңгы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

килешүләрнең бертип формаларына теркәлә торган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзү шарты һәм тәртибе;

хисап финанс елында файдаланылмаган грант калдыклары финанс белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге турында шарт, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, күрсәтелгән чараларга ихтыяҗ булу яисә күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтару турында карар кабул иткәндә, аларда әлеге Тәртипнең 20 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда ихтыяҗ булмаганда;

учреждениенең, учреждение белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы;

бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә грант бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешә алмаганда килешүне өзү хакында шарт.

Министрлык, кирәк булганда, премия лауреатлары белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

Фонд кушылу, кушу яисә үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Грант алучыны бүлү, аерып бирү рәвешендә үзгәртеп оештырганда, шулай ук грант алучы бетерелгәндә килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында

хәбәрнамә булдырып һәм, грант алучы тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган йөкләмәләр һәм грантның файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

13. Бу Тәртипнең 12 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән срокларда килешүгә премия лауреаты исеменнән эш итәргә хокуклы затның имза куюын тәэмин итмәгән очракта, премия лауреаты килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

14. Премия лауреаты, шулай ук премия лауреаты белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю.

15. Учреждениенең, учреждение белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан грант бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән грант бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы;

16. Министрлык, грант бирү турында карар кабул ителгән көннән 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, грантны премия лауреаты тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетларына күчерә.

17. Грант бирүнең нәтиҗәсе - 2025 елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча бер чара уздыру.

18. Премия лауреаты Министрлыкка грант бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешү һәм чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшыра, аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүләрнең үрнәк формаларына теркәлгән формалар буенча бирелә.

Министрлык әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән хисапларны әлеге хисаплар бирелгән көннән 10 эш көненнән артмаган срокта тикшерүне гамәлгә ашыра.

19. Бирелгән грант премия лауреаты тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты тулы күләмдә ачыкланган, грант биргәндә билгеләнгән шартларны бозу, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган очракларда, шулай ук әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән нәтиҗә күрсәткечләренә ирешмәгән очракта Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып эш көннәрендә хисаплана

торган 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарылырга тиеш.

20. Финанс белән тәэмин итү чыганагы грант булган акчаның хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган юнәлешләргә ихтыяҗ булган очракта, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатка премия лауреаты Министрлыкка хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүмат премия лауреатыннан алынган көннән алып 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган грантның калдык өлешен юллауга ихтыяҗ булу яисә булмау турында карар кабул итә.

Министрлык агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган грантның калган өлешен юллау ихтыяҗы булу турында карар кабул иткән очракта, Министрлык һәм премия лауреаты арасында мондый карар кабул ителгән көннән башлап календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә өстәмә килешү төзелә.

21. Премия лауреаты тарафыннан әлеге Тәртипнең 19 һәм 20 пунктларында күрсәтелгән грантны кире кайтару сроклары бозылганда, Министрлык грантны кире кайтару срогы чыккан көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

22. Министрлык премия лауреатының грант бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне башкара.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәгә ирешүне мониторинглау тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.

23. Бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалануны тикшереп тору Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

___